| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ САЛАУССКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛАВЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 83

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча жирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Салавыч авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, Салавыч авыл җирлеге Советының 2018 елның №82 «Салавыч авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын, Салавыч авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 сентябрендәге «Салавыч авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында " гы 19 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2019 елда Салавыч авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

. Иске Салавыч авылында: Нариман, Татарстан урамнары буенча 2 янгынга каршы гидрант урнаштыру, янгынга каршы колонкалар һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу; зират коймаларын ремонтлау; Мәктәп урамы буенча асфальт-бетон өслекле җәяүлеләр тротуарлары урнаштыру; Мәктәп, Татарстан, т.Миңнуллин урамнары буенча юлларны ремонтлау;

- Сәрдегән авылында: Х.Туфан урамы буенча 1 янгынга каршы гидрант урнаштыру, янгынга каршы колонкалар һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу; зиратка илтүче юлны ремонтлау;

-Яңа Салавыч авылында: А.Алиш урамы буенча 1 янгынга каршы гидрант урнаштыру, янгынга каршы колонкалар һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу; А. Алиш урамы буенча юл ремонтлау;

- Биктәш авылында Ю.Гагарин урамы буенча 1 янгынга каршы гидрант урнаштыру, янгынга каршы колонкалар һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу; Ю. Гагарин урамы буенча юл ремонтлау.

Эйе ЮК"

3. Салавыч авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны " Хезмәт» район газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга pravo.tatarstan.ru-авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка хәбәр итәргә, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга кирәк baltasi.tatarstan.ru к

5. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Р.Х.Сибагатуллин